ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 78 һәм 97 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 78 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үзе билгеләгән тәртиптә максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү турында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча хәбәрнамәне үз бюджетына бюджетара трансфертлар ала торган гавами-хокукый оешманың финанс органына (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды белән идарә итү органына) юллый.”;

2) 97 статьяның 4 пунктында:

а) беренче абзацта “субвенцияләр һәм” сүзләреннән соң “, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш,” сүзләрен өстәргә;

б) дүртенче абзацта “субвенцияләр һәм” сүзләреннән соң “, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш,” сүзләрен өстәргә;

в) алтынчы абзацта “субвенцияләр һәм” сүзләреннән соң “, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш,” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 05 март
№ 4-ТРЗ